**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ МАМАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**422104, с.Мамашир,**

**ул. Молодежная,29Б**

**Тел./факс (8 84364) 36-6-04,**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**МӘМӘШИР АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ**

**422104, Мәмәшир ав.,**

**Яшьләр ур.,29Б**

**Тел./факс (8 84364) 36-6-04,**

**e-mail:Mam.Kuk@tatar.ru**

Мәмәшир авыл Җирлеге Советы

К А Р А Р

19 июль 2023 ел №21

Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 апрелендәге 16 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 апрелендәге 16 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының « Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7 нче бүлекнең 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Мәгълүматка керү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары һәм ведомство карамагындагы оешмалар тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә тәэмин ителә.»;

б) 9 нчы бүлектә:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле үзидарә органнары, мәгълүматны урнаштыру өчен, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә туры китереп төзелгән һәм алар буенча кулланучы мәгълүмат сорату җибәрә һәм соралган мәгълүматны ала ала торган электрон почта адреслары күрсәтелгән рәсми сайт булдырылган «Интернет»

челтәрен куллана. Җирле үзидарә органнары карары буенча ведомство карамагындагы оешмалар, федераль законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми сайтлар булдыралар. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар эшчәнлеге турында мәгълүмат Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин»;

түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункты белән тулыландырырга:

«1.1. Җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынган оешмалар «Интернет» челтәрендә үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми битләр булдыралар. Ведомство карамагындагы оешмалар, аларның эшчәнлек өлкәсе үзенчәлекләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары белән килешү буенча үз эшчәнлекләре турында мәгълүматны «Интернет» челтәрендә урнаштыру өчен рәсми битләр булдырмаска мөмкин. «Интернет» челтәрендә әлеге битләр күрсәтелгән рәсми битләр турында мәгълүмат җирле үзидарә органы яки ведомство карамагындагы оешманың рәсми сайтында урнаштырыла.»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге бүлекнең 1 һәм 1.1 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматка чикләнмәгән төркемнең керү хокукын тәэмин итү максатыннан, кулланучылар өчен мәгълүмат булган урыннарда (җирле үзидарә органнары, муниципаль китапханәләр биналарында, башка урыннарда) «Интернет» челтәренә тоташу пунктлары булдырыла.»;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кулланучыларның әлеге бүлекнең 1 һәм 1.1 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматка керү хокукын тәэмин итү максатыннан җирле үзидарә органнары әлеге мәгълүматны Россия Федерациясе законнары нигезендә яклау буенча чаралар күрә.»;

в) 11 нче бүлекнең 10 нчы пунктында «Интернет» челтәрендә» дигән сүзләрне «рәсми сайтларда» дигән сүзләр белән алыштырырга;

г) 14 бүлекнең беренче абзацында «һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен «, җирле үзидарә органнары һәм ведомство карамагындагы оешмалар» сүзләре белән алыштырырга, «хезмәткәрләр» сүзеннән соң «ведомство карамагындагы оешмалар хезмәткәрләре» сүзләре белән тулыландырырга;

д) 2 нче кушымтаны кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл Җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Мәмәшир авыл Җирлеге башлыгы: Әхмәтҗанов И.Г.

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702

«Кукмара муниципаль районы авыл җирлеге Советының 2015 елның 3 апрелендәге 16 номерлы карарына 2 нче кушымта

Рәсми сайтларда урнаштырыла торган Кукмара муниципаль районы « Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге

| N т/б | Мәгълүмат категориясе | Урнаштыруның периодик вакыты |
|---|---|---|
| I. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы « Мәмәшир авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең эшчәнлеге турында гомуми мәгълүмат | | |
| 1. | Районның җирле үзидарә органнарының тулы һәм кыскартылган исеме, кулланучылар тарафыннан соратуларны җибәрү һәм соралган мәгълүматны алу өчен почта адресы, электрон почта адресы, белешмә хезмәтенең, матбугат хезмәтенең телефон номерлары һәм ышаныч телефоны (булган очракта) | Актуаль хәлдә тотыла |
| 2. | Структур бүлекчәләрнең вәкаләтләре, бурычлары һәм функцияләре турында мәгълүмат, шулай ук Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләрен билгели торган норматив хокукый актлар исемлеге | Норматив хокукый һәм башка актларны раслаганнан яки үзгәрткәннән соң, 5 эш көне эчендә Норматив хокукый актлар исемлеге актуаль хәлдә саклана |
| 3. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлек структурасы | Структураны раслаганнан яки үзгәрткәннән соң 5 эш көне эчендә |
| 4. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлек җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) | Билгеләнүдән соң 3 эш көне эчендә. Актуаль хәлдә тотыла |
| 5. | Ведомство карамагындагы оешмаларның исемлеге (булган очракта), аларның бурычлары һәм функцияләре турында мәгълүматлар, шулай ук ведомство карамагындагы оешмаларның почта адреслары, электрон почта адреслары, белешмә хезмәтләренең телефон номерлары, ведомство карамагындагы оешмаларның рәсми сайтлары һәм рәсми битләре турында мәгълүмат (булган очракта) рәсми сайтларның электрон адреслары һәм интернет челтәрендәге әлеге битләрнең күрсәткечләре белән | Оешма төзү турында хокукый актка кул куелганнан соң, 5 эш көне эчендә. Актуаль хәлдә тотыла |
| 6. | «Интернет» челтәрендә әлеге битләр күрсәткечләре булган җирле үзидарә органының рәсми битләре турында мәгълүмат | Актуаль хәлдә тотыла |

| | | |
|---|---|---|
| 7. | Җирле үзидарә органы яки ведомство карамагындагы оешмалар тарафыннан гражданнарның (физик затларның) фикерен ачыклау белән бәйле сораштырулар һәм башка чаралар, җирле үзидарә органы тарафыннан гавами тыңлауларга һәм (яки) җәмәгать фикер алышуына чыгарыла торган мәсьәләләр буенча материаллар, гавами тыңлаулар яки җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре, шулай ук гражданнар (физик затлар) тарафыннан үз тәкъдимнәрен электрон формада җибәрү ысуллары турында мәгълүмат | Гражданнар фикерен ачыклау белән бәйле сораштыру һәм башка чаралар үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң, 5 эш көне эчендә, гавами тыңлаулар яки җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре – җәмәгать тыңлаулары яки җәмәгать фикер алышулары уздырылганнан соң, 3 эш көне эчендә |
| 8. | Җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын (функцияләрен) кулланып үткәрелгән гавами тыңлаулар һәм җәмәгать фикер алышулары турында мәгълүмат | Билгеләнүдән соң 5 эш көне эчендә. Актуаль хәлдә тотыла |
| II. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «_____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең нормалар чыгару эшчәнлеге турында мәгълүмат | | |
| 9. | Кукмара муниципаль районы «_____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан чыгарылган актлар (карарлар, боерыклар, кагыйдәләр, инструкцияләр, нигезләмәләр һәм башка актлар), аларга үзгәрешләр кертү, аларны үз көчен югалткан дип тану, шулай ук дәүләт теркәве турында мәгълүматларны да кертеп | Тиешле документны кабул иткәннән (раслаганнан) соң, 5 эш көне эчендә. |
| 10. | Кукмара муниципаль районы «_____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларын гамәлдә түгел дип тану турындагы эшләр буенча суд карарлары турында мәгълүмат | Суд карары җирле үзидарә органнарына кергәннән соң, 5 эш көне эчендә |
| 11. | Муниципаль хезмәтләрнең административ регламентлары һәм стандартлары | Аларны паслаганнан соң 5 эш көне эчендә. |
| III. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «_____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең агымдагы эшчәнлеге турында мәгълүмат | | |
| 12. | Муниципаль хезмәтләр һәм аларны күрсәтү (башкару) тәртибе турында мәгълүмат | Актуаль хәлдә тотыла |
| 13. | Кукмара муниципаль районы «_____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге эшчәнлегенең планнары һәм күрсәткечләре | Планны һәм күрсәткечләрне раслаганнан соң, 5 эш көне эчендә |
| 14. | Федераль максатчан һәм (яисә) дәүләт программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре, максатчан күрсәткечләрне үтәү, максатчан һәм (яисә) дәүләт финанс ресурслары программасын үтәүгә тотылган күләмнәр, шулай ук программа чараларын гамәлгә ашыру мониторингы нәтиҗәләре турында төп мәгълүматлар | Квартал саен |
| 15. | Кукмара муниципаль районы «_____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында мәгълүмати һәм аналитик | Актуаль хәлдә тотыла |

| | | |
|---|---|---|
| | материаллар (докладлар, хисаплар һәм мәгълүмати характердагы күзәтүләр) | |
| 16. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының башка җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, сәяси партияләр, һөнәри берлекләр һәм башка оешмалар, шул исәптән халыкара оешмалар белән хезмәттәшлеге турында мәгълүмат | Актуаль хәлдә тотыла |
| 17. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җитәкчесенең һәм рәсми делегацияләрнең рәсми визитлары һәм эш сәфәрләре, шулай ук муниципаль берәмлек оештырган рәсми чаралар (утырышлар, очрашулар, брифинглар, семинарлар, "түгәрәк өстәлләр" һәм башка чаралар) турында мәгълүмат, аерым алганда, булачак рәсми визитлар һәм эш сәфәрләре анонслары, рәсми чаралар һәм аларның нәтиҗәләре | Рәсми визит (эш сәфәре, рәсми чара) анонслары<br>- әлеге чаралар башланганчы, бер эш көне дәвамында. Рәсми визит (эш сәфәре, рәсми чара) нәтиҗәләре<br>- әлеге чаралар тәмамлангач, бер эш көне дәвамында. |
| 18. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җитәкчесенең рәсми чыгышлары һәм белдерүләренең текстлары һәм (яки) видеоязмалары | Чыгыштан соң, бер эш көне эчендә |
| 19. | Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау торышы һәм аларның иминлеген тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар, фаразланган һәм барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр, алардан халыкны саклау алымнары һәм ысуллары турында мәгълүмат | Актуаль хәлдә тотыла |
| IV. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең эшчәнлеге турында статистика мәгълүматы | | |
| 20. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан файдалану турында мәгълүмат | Квартал саен |
| V Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы тарафыннан оештырылган координацион һәм киңәшмә органнары турында мәгълүмат | | |
| 21. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы тарафыннан оештырылган координацион һәм киңәшмә органнары исемлеге | Органнарны төзегәннән соң, 5 эш көне эчендә. |
| 22. | Координацион һәм киңәшмә органнары эшчәнлеген булдыруны һәм хокукый нигезен көйләүче норматив хокукый һәм башка актлар | Норматив хокукый актларга кул куелганнан соң, 5 эш көне эчендә |
| 23. | Координацион һәм киңәшмә органнары составы (фамилияләр, исемнәр, ата исемнәре, | Норматив хокукый актларга кул куелганнан соң, 5 эш көне |

| | | |
|---|---|---|
| | координацион һәм киңәшмә органнары җитәкчеләре һәм әгъзалары вазыйфалары), шулай ук урнашкан урыны, телефон (факс) номерлары, электрон почта адресы турында мәгълүмат | эчендә |
| 24. | Координацион һәм киңәшмә органнары утырышлары турында мәгълүмат, аерым алганда, утырышлар анонслары, координацион һәм киңәшмә органнары утырышлары беркетмәләре | Утырышка кадәр кимендә 3 эш көне алдан утырыш анонслары Беркетмәгә имза салганнан соң, 5 эш көне эчендә утырышлар беркетмәләре |
| VI. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кадрлар белән тәэмин ителеше турында мәгълүмат | | |
| 25. | Гражданнарның муниципаль хезмәткә керү тәртибе | Актуаль хәлдә тотыла |
| 26. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә булган муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат | Вакантлы вазыйфа игълан ителгәннән соң, 3 эш көне эчендә |
| 27. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатларга квалификация таләпләре | Таләпләрне раслаганнан соң, 5 эш көне эчендә |
| 28. | Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс шартлары һәм нәтиҗәләре | Конкурс шартлары конкурс уздырылганчы кимендә 5 эш көн алдан урнаштырыла. Нәтиҗәләр – конкурс үткәрелгәннән соң, 3 эш көне эчендә |
| 29. | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә вакантлы вазыйфаларны биләү мәсьәләсе буенча мәгълүмат алу өчен телефон номерлары, электрон почта адресы | Актуаль хәлдә тотыла |
| 30. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар оештыру һәм үткәрү буенча комиссияләр составы | Комиссия составын раслаганнан соң, 5 эш көне эчендә |
| 31. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс нәтиҗәләренә шикаять бирү тәртибе | Тәртипне раслаганнан соң, 5 эш көне эчендә |
| 32. | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге карамагындагы белем бирү учреждениеләре исемлеге (булган очракта), аларның әлеге белем бирү учреждениеләре турында белешмә характердагы мәгълүмат алырга мөмкин булган | Актуаль хәлдә тотыла |

| | | |
|---|---|---|
| | почта адресларын, рәсми сайт адресларын, шулай ук телефон номерларын күрсәтеп, | |
| 33. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә ришвәтчелеккә каршы чаралар турында мәгълүмат | Актуаль хәлдә тотыла |
| VII. Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең гражданнар (физик затлар), оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләт органнары мөрәҗәгатьләре белән эшләве турында мәгълүмат | | |
| 34. | Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар (физик затлар), оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгатьләре белән эшләү мәсьәләләрен көйли торган норматив хокукый һәм башка актлар | Норматив хокукый һәм башка актлар раслаганнан соң, 5 эш көне эчендә |
| 35. | Гражданнар (физик затлар), оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе | Актуаль хәлдә тотыла |
| 36. | Гражданнарны (физик затларны), шул исәптән оешма вәкилләрен (юридик затларны), иҗтимагый берләшмәләрне һәм дәүләт органнарын кабул итү тәртибе һәм вакыты | Тәртипне раслаганнан соң, 5 эш көне эчендә |
| 37. | Гражданнарның, шул исәптән оешма, иҗтимагый берләшмә һәм дәүләт органнары вәкилләренең мөрәҗәгатьләренә күзәтүләр, шулай ук әлеге мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре һәм кабул ителгән чаралар турында гомумиләштерелгән мәгълүмат | Квартал саен |
| VIII. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге карамагындагы муниципаль мәгълүмат системалары турында мәгълүмат | | |
| 38. | Муниципаль мәгълүмат системаларын булдыру, алып бару тәртибен көйли торган норматив хокукый һәм башка актлар, шулай ук кызыксынучы затларның Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге карамагындагы муниципаль мәгълүмат системаларындагы мәгълүматка керү тәртибе | Норматив хокукый һәм башка актларга кул куелганнан соң, 5 эш көне эчендә |
| 39. | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә «Интернет» челтәрендә урнаштырылырга тиешле Кукмара муниципаль районы «____________ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында башка мәгълүмат | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән срокларда |